**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**Троицко-Урайского**
**сельского поселения**
**Рыбно-Слободского**
**муниципального района**
422649, Республика Татарстан, Рыбно-Слободский район, с.Трой-Урай, ул.Прикамская, д.9

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Трой-Урай авылҗирлеге**
**Башлыгы**
422649, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Трой-Урай авылы, Кама буе урамы,9 йорт

Тел.: (84361) 24320, факс: (84361)24320, e-mail: Tur.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru


10.11.2025 Троицкий-Урай №3

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Троицкий-Урай авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Троицкий-Урай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 21 ноябрь 9 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий-Урай авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

2. 2025 елның 21 ноябрь 11 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий-Урай авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

3. 2025 елның 21 ноябрь 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий-Урай авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены өченче этабын үткәрүне билгеләргә.

4. 2025 елның 21 ноябрь 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены дуртенче этабын үткәрүне билгеләргә.

5.Халык җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге составына керүче Трой-Урай, Гремячка авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы»:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктларның башка территорияләрен төзекләндерү;

- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

«каршы» «риза»

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Трой-Урай авылы, Мәктәп урамы, 13 нче йорт,Кама – буе урамы,9 йорт;Гремячка авылы, Александров урамы 24 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе  муниципаль районының
Трой-Урай авыл җирлеге башлыгы Мухаммаджанов Р.М.